# ТАТАРСТАНДА ИКЕТЕЛЛЕЛЕК МӘСЬӘЛӘСЕ: АМЕРИКАДАГЫ ТЕЛ СИТУАЦИЯСЕ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРЫП

**Лили Герберт**

Төньяк Каролина университеты (АКШ)

chulpanljh@gmail.com

**Г. А. Нәбиуллина**

Казан федераль университеты, Казан шәһәре (Россия)

GuzelNab2@yandex.ru

*В статье рассматривается ситуация двуязычия в Татарстане и в Америке. В частности отмечаются результаты преподавания татарского языка в Татарстане и других иностранных языков в американских государственнных школах.*

*Татарский язык, русский язык, английский язык, билингвизм, государственный язык*

Татарстанда ике дәүләт теле булса да, чынлыкта рус Һәм татар телләренең функциональ рольләре аерыла. Заманча Татарстандагы икетеллелек турында фәнни әдәбиятта дәүләт планында татар телен үстерүгә басым ясала. Л. К. Бәйрәмова язганча, һәм руслар да, Һәм татарлар да гомуми аралашу юлы буларак рус телен кулланалар. Аерып әйткәндә, татар теле руслар өчен чит тел кебек. Шуңа күрә, Татарстанда күп кеше татар телен функциональ дәрәҗәдә кулланмый. Кешеләр татар телен төрле дәрәҗәләрдә белгәнгә күрә, тел ассиметриясе Татарстанда плюрализм хәлен тудыра, һәм ике теллелекнең берничә төре була [Байрамова 2001: 232-233]. Татар телен саклау өчен, институтлардагы белемле татар кадрларының әҺәмиятлелеген билгелиләр [Замалетдинов 2006: 83-84].

Америкада дәүләт, академик һәм бәйсез организацияләр илне саклау Һәм икътисад үстерү өчен, телләр белү кирәк дип билгелиләр. Әдәбиятта ике

теллелекнең жәмгыять Һәм акыл өчен файдалларын белдерәләр: тел, акыл, һәм социаль күнекмәләр берьюлы үсә; картлыкта ике теллелек акылны тәэмин итәргә мөмкин [Bialystok, Craik, Luk 2012]; һәм балаларга ике теллелек эффектив аралашуны үстерү өчен бик файдалы [Siegal, Surian, Matsuo, Geraci, Iozzi, Okumura, Itakura 2010]. Мәгариф өлкәсендә баланың туганнан бер тел генә түгел, ә ике тел өйрәнү мөмкинлеген күрсәтәләр [Byers-Heinlein, Burns, Werker 2010]. Ике теллелекнең әһәмиятен истә тотып, күптән түгел Америкада тел өйрәнү өчен, берничә махсус программа төзелгән. Аларның кайберсе студентлар, аспирантлар һәм укытучылар өчен дәүләт программалары. Ләкин программалар өчен дәүләтнең гомуми план булмаганын билгелиләр. Икенче яктан, укучылар өчен мәктәптәге икетелле программалар хуплана. Америкада «икеюллы» моделе 1960 нчы елларда башланган булса да, 1990 нчы еллардан гына үсеп, моңа күп галимнәр игътибар итә башлый.

Америкада предметларны инглизчә дә, чит телдә дә өйрәтәләр. Ике модель бар: беренче сыйныфтан дәресләр 50% чит телдә, 50% инглиз телендә; яисә беренче сыйныфларда дәресләр 90% чит телдә, 10% инглиз телендә, һәм югары сыйныфларда (4 нче – 6 нчы) инглиз телендә күбрәк өйрәтәләр. Максатлар күп: чит ил укучыларын (иммигрантларны) инглизчә өйрәтү; аларның туган телен саклап, башка американнарны чит телгә өйрәтү; иммигрант Һәм америка укучылары арасындагы уңай мөнәсәбәтләр төзү. Чит ил яисә америкалы булганга карамастан, гомуми икеюллы программалар бетергән укучылар имтихан нәтиҗәләре буенча һәм инглиз дә, һәм чит телне дә башкалардан яхшырак беләләр. Алга таба бер телдәге белем һәм күнекмәләр икенче телдә кулланырга мөмкин. Уңай нәтиҗәләр булса да, ике юллы программалар буенча укучылар барыбыр күбрәк инглиз телен өйрәнәләр, һәм ахырында испанча Һәм башка чит телләрне инглизчәдән начаррак беләләр. Тикшеренү шуны күрсәтә, чит телдәге дәресләрдә материалны инглизчә еш аңлаталар һәм аралашалар. Шунысы да ачык: бу күренеш укучыларның тел белеме белән бәйле. Чит ил укучыларының

инглизчәсе америкaн укучыларының испанчасыннан яхшырак булганга күрә, укучылар бергә инглизчә сөйләшәләр. Инглиз теленең йогынтысын һәм социаль престиж аркасында, мәктәптә чит телне өйрәнү көчлерәк хуплау кирәк, дип белдерелә. Укучы нәтиҗәле өйрәнсен өчен, иммигрант укучыларына чит телне инглиз теленнән күбрәк тыңларга Һәм укырга кирәк. Гомумән, икеюллы программа укучыларга ошаса да, нәтиҗәдә, алар инглиз телендә күбрәк өйрәнеп, чит телләрне функциональ дәрәҗәдә куллана белмиләр.

Татарстан Һәм Америкадагы тел ситуацияләре нигездә аерыла. Татар теле Татарстандагы күпчелек өчен милли тел булса да, халкының кайберсе татарча белмәгән сәбәпле, русчаны халыкара һәм мәдәниятара тел буларак кулланалалар. Шунлыктан татар телендә күп ситуацияләр төрле-төрле дәрәҗәләрдә сөйләшәләр. Американың башлангычыннан рәсми аралашу өчен инглиз теле кулланылган иде. Америкада закон буенча рәсми булмаган телләр – инглизчә сөйләшүчеләрнең күбесе өчен инглиз теленнән башка телләр – яңа һәм чит кебек тоела (Африкадан алган колларның Һәм тамыр американнарның телләренә карамастан). Башкача әйткәндә, егерме гасырның уртасына кадәр әдәбиятта Һәм сәясәттә шулай саналган: америкалыларга иммигрантларның телен һәм мәдәниятен өйрәнергә кирәк. Киресенчә, ассимиляция процессы буенча иммигрантларны инглизчә өйрәтергә кирәклеге нык хупланылган.

Хәзерге вакытта Татарстанда, мәдәният байлыгын саклау өчен, татар теле өйрәнүгә басым ясала. Америка халкы исә тел белеменең ресурсларын сакларга һәм зурларга тырыша. Максатлар һәртөрле булса да, Татарстанда да, Америкада да халыкара телдән башка телне өйрәтүгә бәйләнгән проблемалар бар. Укучылар арасында гомуми җәмгыятьтә әзрәк престижлы телне өйрәнү мотивациясе үссен өчен, телне өйрәнгәндә, көнкүреш ситуацияләрдә татар яисә чит телне кулланырга кирәк, дип билгеләнә. Америкада инглизчә социаль престижлы һәм күбрәк укучылар инглизчә чит телдән яхшырак беләләр дип, хәтта мәктәптәге ике теллелек программаларында чит телләрне функциональ дәрәҗәдә өйрәнмиләр.

Татарстанда да шулай: русча халыкара тел булганга күрә, туганнан татарча белмичә һәм даими кулланмыйча, укучылар өчен татар телендә функциональ сөйләшергә кыен.

Татарстан Һәм Америкадагы тел ситуациясе турында күп фәнни әдәбият булса да, күбрәк акыл һәм регион эчендә мәдәниятара мөнәсәбәтләр өчен файдаларга басым ясалган. Ләкин ике теллелекнең гомуми мәдәниятара мөнәсәбәтләрне аңлаудагы роле турында тикшеренү җитми. Шуңа күрә, тел өйрәнүдән телне генә түгел, ә мәдәни белемен дә тикшерергә кирәк. Икенче тел өйрәнгән сәбәпле, укучылар һәм башка мәдәниятларның кешеләрнең аралашуын да, һәм үз мәдәниятенең үзенчәлекләрен дә аңлый башлый. Алар мәдәни аермаларын аңлып, һәртөрле рәвешчә аралашкан һәм яшәгән кешеләр арасында уртак телне таба алалар. Минемчә, бу белем укучыларны аеруча үзгәрткәнне күбрәк тикшерергә кирәк: укучылар дәрестән тыш көнкүреш ситуацияләрдә белемнән файданы күргәндә, ничек аларның тел өйрәнү өчен мотивациясе үзгәрергә мөмкин.

## Әдәбият


1. Байрамова Л. К. Татарстан: языковая симметрия и ассиметрия. – Казань: Изд-во Казанского университета, 2001. – 232-233 с.
2. Замалетдинов Р. Р. Билигвализм и полилингвализм в сфере высшего образования // Высшее образование в России. – 2006. – № 6. – С 82-85.
3. Bialystok, E., Craik, F.I.M., & Luk, G. (2012) Bilingualism: Consequences for Mind and Brain. *Trends in Cognitive Science, 16*(4). 240-250. doi: 10.1016/j.tics.2012.03.001.
4. Byers-Heinlein, K., Burns, T.C., & Werker, J.F. (2010). The Roots of Bilingualism in Newborns. *Psychological Science, 21*(3). 343-348. doi: 10.1177/0956797609360758.
5. Siegal, M., Surian, L., Matsuo, A., Geraci, A., Iozzi, L., Okumura, Y., & Itakura, Shoji. (2010). Bilingualism accentuates children’s conversational understanding. *PLoS One, 5*(2). doi: 10.1371/journal.pone.0009004.